КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 ноябрь г.Казань № 971

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 522 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 522 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 август, 855 нче; 2023 ел, 20 ноябрь, 1491 нче; 2024 ел, 7 май, 311 нче; 2024 ел, 9 сентябрь, 744 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә, аңа түбәндәге эчтәлекле $24^1$ һәм $24^2$ пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«$24^1$. Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар, гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару объекты территориясен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 24 сәгать трансляцияли, агымдагы режимда объекттагы эшләрнең үтәлешен күзәтергә мөмкинлек бирә торган техник таләпләргә туры килә торган кимендә ике видеокүзәтү онлайн камера белән җиһазландырып, видеокүзәтү белән тәэмин итәргә тиеш.

$24^2$. Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасы (алга таба – цифрлы платформа) ярдәмендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару һәм реализацияләү күләмнәрен исәпкә алуны тәэмин итәргә тиеш.

Цифрлы платформаны эксплуатацияләү тәртибе, цифрлы платформада урнаштырыла торган мәгълүматны бирү тәртибе һәм аның исемлеге Вәкаләтле органның норматив хокукый актында билгеләнә.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин